**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче Таш-Кичү торак пунктында 2022 елда узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

23 ноябрь 2022 ел № 4

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 22 ноябрендә узган Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче Таш-Кичү торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча сез ризамы, дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде:

-Таш Кичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 98 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 52 кеше кертелгән, бу 53,1 % тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 52 кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче Таш-Кичү торак пунктында гражданнарның җыены узган һәм һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип кабул итәргә.

2. Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенә керүче Таш-Кичү торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча сез ризамы:
-Таш Кичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).» - сораулары буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Бу карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев